ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОСПАССКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молождежная, д. 13, с. Новоспасск, 423535

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА СПАС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Молодежная урамы, 13 нче йорт,
Яңа Спас авылы, Зәй районы, 423535
ИНН/КПП: 1647011467/164701001

Телефон, факс 64-5-48. Электронный адрес: Nspas.Zai@tatar.ru, сайт: ww.zainsk.tatarstan.ru/rus/novospasskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«25» октября 2021 г.** **№25**

**2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалану һәм аларны саклау муниципаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклауны гамәлгә ашыру максатында, Россия Федерациясе Җир кодексының 11, 13 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2007 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалану һәм аларны саклау" муниципаль программасын расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе Н.В.Танчук

Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның "25" октябрьендәге 25 номерлы карарына кушымта.

**"2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалану һәм аларны саклау" муниципаль программасы**

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез | РФ Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Заказчы | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаның төп максаты | Яңа Спас авыл җирлеге җирләрен саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану чараларын гамәлгә ашыру |
| Программаның билгеләнеше | Яңа Спас авыл җирлеге җирләрен саклау мәсьәләләрен хәл итү |
| Программаны гамәлгә ашыру срогы | 2021-2023 еллар |
| Көтелә торган нәтиҗәләр | Бозылган җирләрне торгызу, халыкның экологик иминлеген һәм көнкүреш сыйфатын яхшырту |
| Программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны гамәлгә ашыру механизмы | Җирләрне саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану буенча җир хуҗаларының һәм кулланучыларның эшчәнлеген координацияләү Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла. Программаны төгәлләштерү кирәк булган саен уздырыла |

| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары, елларга бүлеп | Финанслау чыганагы | Еллар | | | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | 2021 | 2022 | 2023 | |
| | Җирле бюджет | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 3000,00 сум |
| | Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм муниципаль бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. | | | | |

## 1. Муниципаль программаны тормышка ашыруның тиешле өлкәсендә агымдагы торышка характеристика һәм төп проблемалар

Җир - әйләнә-тирә мохитнең мөһим өлеше, аннан файдалану башка табигать объектлары: хайваннар, урманнар, үсемлекләр дөньясы, сулар, файдалы казылмалар һәм җир асты байлыкларының башка кыйммәтләре белән бәйле. Җирдән файдаланмыйча һәм аны сакламыйча гына башка табигый ресурслардан файдалану мөмкин түгел. Җиргә карата хуҗасыз караш озак көттерми, зыян сала яки якын киләчәктә әйләнә-тирә мохиткә зарар китерә, җирнең өске катламы - туфракны җимерүгә, аның химик һәм радиоактив пычрануына гына түгел, ә бөтен табигать комплексының экологик начараюына китерергә мөмкин.

"2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалану һәм аларны саклау" муниципаль программасы (алга таба – Программа) җир ресурсларыннан нәтиҗәле һәм рациональ файдалану һәм икътисадны ныгыту мәнфәгатьләрендә идарә итү буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итә торган җирләрне куллану һәм саклау өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Җир фондының шактый күләмен төрле максатларда файдалану әйләнә-тирә мохит экосистемасының барлык звеноларының табигый бөтенлеген саклау буенча билгеле бер бурычлар йөкли. Табигатьтә барысы да үзара бәйләнгән. Шуңа күрә бер звеноның дөрес эшчәнлеген бозу, урман булсынмы ул, хайваннар дөньясы, җир булсынмы, экосистеманың дисбалансына һәм бөтенлеге бозылуга китерә.

Җирдән рациональ файдаланмау, аңа куллану объекты итеп һәм хуҗасыз караш ул башкара торган функцияләр бозылуга, табигый үзлекләрнең кимүенә китерә.

Җирләрдән рациональ файдалану тәэмин ителгәндә генә җирләрне саклау нәтиҗәле була ала.

Җирлекнең тотрыклы социаль-икътисадый үсеш проблемалары һәм җирлек халкының экологик яктан имин яшәеше хәзерге этапта җирләрне саклау һәм файдалану мәсьәләләрен хәл итү белән тыгыз бәйләнгән.

Җирлек территориясендә төрлечә рөхсәт ителгән файдаланудагы җир кишәрлекләре бар.

Авыл хуҗалыгы җирләренә кергән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр аеруча кыйммәтле санала.

Җирлек территориясендәге көтүлекләр техник торышы буенча нигездә чиста дип санала. Көтүлекләр шәхси ярдәмче хуҗалыклар тарафыннан файдаланыла.

Көтүлекләрдәге яшел азыктан кулланучыларның барысын да исәпкә алганда, табигый көтүлекләргә кытлык юк. Җирлекнең барлык көтүлекләрендә яшел үлән җитәрлек.

Җирләрнең экологик торышы уртача яхшы дип бәяләнә, әмма стихияле төстә барлыкка килгән рөхсәтсез чүплекләр әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый һәм экологик хәлне катлауландыра.

## 2. Муниципаль программаны тормышка ашыруның максатлары, бурычлары һәм максатчан күрсәткечләре, сроклары һәм этаплары

Җирлек территориясендә җирләрдән файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль сәясәтнең төп принциплары булып түбәндәгеләр тора: җирлек башкарма комитеты эшчәнлегенең законлылыгы һәм ачыклыгы, хисаплылык һәм контроль, нәтиҗәлелек.

Муниципаль программаның максаты җирләрне һәм туфракны пычрату, ярлыландыру, деградацияләү, бозу, юк итү һәм җиргә һәм туфракка башка тискәре йогынтыны кисәтү, булдырмый калудан, шулай ук җирләрдән, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен, рациональ файдалануны тәэмин итүдән гыйбарәт.

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:
- җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекне оптимальләштерү;
- җирләрдән файдалану һәм саклауның нәтиҗәлелеген арттыру, җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны оештыру;
- яшел үсентеләрне саклау һәм торгызу;
- җирләрне инвентаризацияләү.

Җирләрне инвентаризацияләү җирләрне деградацияләү, пычрату, чүпләү, бозу, хуҗалык эшчәнлегенең башка тискәре (зарарлы) йогынтысын булдырмау, максатчан кулланылмаган яки кулланылмаган җир кишәрлекләрен, җирләрнең башка характеристикаларын рөхсәт ителгәнчә файдаланылмауны ачыклау максатыннан башкарыла.

Әлеге программаны тормышка ашыру җирдән файдалануны тәртипкә салуга, яңа җир кишәрлекләрен әйләнешкә кертүгә, авыл җирлегенең инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыруга, икътисадны үстерүгә, җирләрне нәтиҗәле файдалануга һәм саклауга ярдәм итәчәк.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр тәэмин ителәчәк:

1) торак пунктларны төзекләндерү;
2) җирләрнең сыйфат характеристикалары яхшыру;
3) җирләрдән нәтиҗәле файдалану.

Программаны гамәлгә ашыру срогы - 2021-2023 еллар.

## 3.Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны гамәлгә ашыру җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла. Программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның еллык күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турында Совет карары белән раслана.

Программада каралган чаралар исемлеге җирлек башкарма комитеты тарафыннан төзәтелергә мөмкин.

| Чыганаклар һәм чыгымнар юнәлешләре | Финанслау күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барысы | шул исәптән елларга бүлеп | | |
| | | 2021 | 2022 | 2023 |
| Җирле бюджет | 3000,00 | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 1000,00 сум |

## 4.Муниципаль программаның төп чаралары исемлеге

Муниципаль программа кысаларында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклауның һәм алардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру буенча түбәндәге чаралар планлаштырылган:

| N п\п | Чараның исеме | Финанслау чыганагы | Башкаручы | Башкару срогы | Җаваплы зат |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Җирлек территориясендә җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдаланмау яисә алардан файдаланмау фактларын ачыклау максатында җир кишәрлекләрен карау | Финансламыйча | Авыл җирлеге башкарма комитеты | Ел саен 1 июльгә кадәр | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2. | Авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану тәртибен җайга сала торган норматив актларның үтәлешен тикшерү | Финансламыйча | Авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2023 еллар | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының җир законнары нормаларын гражданнар җыеннарында аңлату | Финансламыйча | Авыл җирлеге башлыгы | Елга бер мәртәбә | Авыл җирлеге башлыгы |
| 4. | Җирлекнең торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү | Авыл җирлеге бюджеты | Авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2023 еллар | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 5. | Авыл хуҗалыгы җирләрен агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре басып китүдән саклау һәм зарарлы организмнардан яклау чаралары үткәрү | Җирдән файдаланучылар ның үз средстволары | Җирнең урнашу урыны буенча | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |